ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ВАХИТОВСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
ВАХИТОВ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА
КОМИТЕТЫ

Ул. Центральная, д.28, д. им. М. Вахитова, 422575

Үзәк ур., 28 нче йорт, М. Вахитов исем авылы, 422575

Тел.: (84379) 30-1-48, факс: (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

_______________ д. им. М. Вахитова _______________

Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Җирләү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 декабрендәге 8-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясындагы 3 пункты һәм 12 статьясындагы 3 пункты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында җирләү һәм күмү эше турында» Федераль законны гамәлгә ашыру чаралары турында» 2007 елның 18 маендагы 196 номерлы һәм 2010 елның 15 июненнән 468 номерлы карарлары, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлеге Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Югары Ослан муниципаль районының Вахитов авыл җирлегендә 2024 елның 1 февраленнән җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен 8370,20 сум күләмендә расларга һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үземә калдырам.

Вахитов авыл җирлеге башлыгы — Кәримов Ф. Р.

Татарстан Республикасы
Югары Ослан муниципаль районы
Вахитов авыл җирлеге
Башкарма комитетының
2024нче елның 26нчы гыйнварыннан
11нче номерлы карарына
1нче кушымта

Югары Ослан муниципаль районында 2024нче елның 1нче февраленнән җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияле исемлеге бәяләре

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
| --- | --- |
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,00 |
| 2. Күмү өчен кирәкле табутны һәм башка предметларны бирү һәм китерү | 3183,60 |
| 3. Мәрхүмнең гәүдәсен (калдыкларын) зиратта күчерү | 1360,74 |
| 4. Зиратта җирләү (кабер казу һәм күмү) | 3825,86 |
| Барлыгы | 8370,20 |